**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 28 декабрь № 993

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 11 ноябрь, 850 нче карары белән расланган Югары белем бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары белем бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 11 ноябрь, 850 нче карары белән расланган Югары белем бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның 1.2.3 пунктчасындагы икенче абзацта «халыкара олимпиада» сүзләрен «яки халыкара олимпиада, тиешле олимпиада үткәрелгән елдан соң килүче дүрт ел эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

4.15 пунктның җиденче абзацында «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Россия Федерациясенең югары уку йортларын тәмамлап чыгучыларның йомгаклау дәүләт аттестациясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2003 ел, 25 март, 1155 нче приказы белән расланган нигезләмәгә таянып,» сүзләрен «2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керәчәк Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Югары белемнең белем бирү программалары – бакалавриат программалары, белгечлек программалары һәм магистратура программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 29 июнь, 636 нчы боерыгы белән расланган тәртип нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

12.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.2. Шикаять почта аша, күпвазыйфалы үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтә торган югары белем бирүче мәгариф оешмасының йә югары белем бирүче мәгариф оешмасына дәүләт йөкләмәсе биргән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органының

рәсми сайты аша, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә алынырга мөмкин.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\993.docx